СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРЖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

21.03.2023 Әгерҗе шәһәре № 27-5

Җир кишәрлеген арендалау шартнамәсен төзү хокукына аукцион предметының башлангыч бәясен билгеләү турында

Россия Федерациясе Җир кодексының 39.11 статьясындагы 14 пункты, «Россия Федерациясендә бәяләү эшчәнлеге турында» 1998 елның 29 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә җир кишәрлекләреннән нәтиҗәле файдалану максатларында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Әгерҗе муниципаль районы территориясендә урнашкан, дәүләт кадастр бәяләү нәтиҗәләре аукцион үткәрү турында Карар кабул ителгән көнгә кадәр биш елдан да иртәрәк расланмаган, Татарстан Республикасы «Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль милектә булган яки дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәсен төзү хокукына аукцион предметының башлангыч бәясен түбәндәгечә билгеләргә:

- торак пунктлар җирләренә кертелгән һәм шәхси ярдәмче хуҗалык (ШЯХ) өчен файдаланыла торган мондый җир кишәрлегенең кадастр хакының ун проценты;

- Торак пунктлар җирләренә кертелгән һәм индивидуаль торак төзелеше (ИТТ) өчен кулланыла торган мондый җир кишәрлегенең кадастр хакының егерме биш проценты.

2. Татарстан Республикасы “Әгерҗе муниципаль районы” муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәсен төзү хокукына аукцион предметының башлангыч бәясен яки Әгерҗе муниципаль районы территориясендә урнашкан, әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелмәгән категорияләр җирләренә кертелгән дәүләт милке чикләнмәгән, «Россия Федерациясендә бәяләү эшчәнлеге турында» 1998 елның 29 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә базар бәяләве нәтиҗәләре буенча билгеләнгән еллык аренда түләве күләмендә билгеләргә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре, экология, табигый ресурслар һәм аграр мәсьәләләр буенча даими комитетына йөкләргә.

Совет Рәисе урынбасары
Муниципаль район Башлыгы урынбасары И.И. Ямалиев